БӘҺАСЕЗ МИРАС

Татарстан белән ЮНЕСКО арасындагы хезмәттәшлек юнәлешләре барланды

> 2

«ИКЕНЧЕ ИКМӘК»

Ил-көндәге вазгыять авыл кешесенең бәрәңгегә булган мөнәсәбәтен дә үзгәртмәгәе...

> 2

ЯШЬЛЕК ИЛЕ

«Татнефть»нең «сандугач»лары нинди була?

> 4

ЯЗУЧЫ ФИКЕРЕ

«Үз балтасы булмаган адәм кеше балтасының кадерен белми»

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 48 (28821) | Чәршәмбе | 6 апрель | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

КИҢӘШ БУЛСА, ЭШ КӨТТЕРМӘС

Яшәеш

Халык фикере – беренче урында! Парк һәм скверлар да, ишегаллары – барысы да татарстанлыларның фикерен исәпкә алып төзелә, төзекләндерелә. Хөкүмәт йортында узган очрашуда Татарстанның төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры Марат Айзатуллин бу хакта кабат искәртте.

dvor.tatar

– Быел Татарстанда 1200 ишегалды төзекләндереләчәк. Моның өчен 9 млрд сум акча тотылачак. Илдәге вазгыять бу юнәлешкә тискәре йогынты ясамады. Без планны үтәячәкбез. Нинди дә булса эшне кыскарту булмаячак, – диде ул.

Министр сүзләренчә, «Безнең ишегалды» программасына Россиядә дә тиңнәр юк. Исегезгә төшерәбез: программа Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов кушуы буенча, 2020 елда эшли башлады.

– Шушы ике ел эчендә 2167 ишегалды яңартылды. Әлеге эшләр өчен 16 млрд сумнан артык акча тотылды. Без ишегалларын тәртипкә китереп, 660 мең кешенең тормыш шартларын яхшырттык дисәк тә була. Биредә яшәүчеләр өчен уңайлы, төзек ишегалды булу – үзе зур шатлык, – ди министр.

Дөрес, халык белән гел уртак тел табып булмый икән. Программаның координаторы, «Татарстан шәһәрләре үсеше институты» фонды директоры урынбасары Венера Камалова әйтүенчә, бер йортта яшәүчеләр дә үзара килешә алмый икән әле. Шулай булгач, белгечләргә кайчак халык белән озак бәхәсләшергә, аларны күндерергә туры килә. Уртак тел тапмаган чаклар да булган. Узган ел Казанның Авангард урамында яшәүчеләргә дөрес куелмаган балалар мәйданын башка урынга күчерергә тәкъдим иткәч, алар «Безнең ишегалды» программасыннан бөтенләй баш тартканнар.

Быел тәртипкә китерәсе бер ишегалдында яшәүчеләр төзекләндерү эшләрен 2023 елга күчерүне сораган. Алар җирнең хуҗасын ачыклау буенча суд юлында йөриләр.

– Президент программасы буенча нинди ишегаллары төзекләндерелергә тиеш икәнне яңадан искә төшереп үтәм. Бу программада 2014 елга кадәр төзелгән йорт ишегаллары катнаша ала. Әмма бер шарты бар: моңарчы аларда бернинди төзекләндерү эшләре үтмәве кирәк, – ди Венера Камалова. – Төзекләндерү эшләре башка еллардагы кебек, үзгәрмәде. Программага йортка илтүче юлларны һәм тротуарларны төзекләндерү, утыргычлар, чүп савытларын яңарту, урам баганаларындагы утларны алыштыру, кирәк урында яктырткычлар кую, балалар мәйданчыгы булдыру, спорт җиһазлары урнаштыру, чүп ташлау өчен мәйданнар булдыру, кер элү һәм кагу өчен махсус урыннар ясау керә.

Халык үзе яшәгән ишегалларын ничек үзгәртергә теләве хакында фикерен җиткерә ала. Моның өчен мөмкинлекләр җитәрлек. Быелның 15 апреленнән 30 майга кадәр теләгән һәр кеше 2023 елда яңартылачак парк һәм скверлар, ишегаллары өчен тавыш бирә ала. Сезнең ишегалды ул исемлеккә кергәнме-юкмы икәнне dvor.tatar. сайтыннан яки 8 (800) 275-2020 телефоны аша шалтыратып белешеп була. Сораштыруда 204 иҗтимагый киңлек, 3087 ишегалды катнашачак. Тагын шунысы да бар: аларның 200ен халык үзе сайлап алачак. Калганнарын БТИ мәгълүматларына карап сайлап алачаклар. Яңарту беренче чиратта зарур булган урыннар киләсе елдагы исемлеккә эләгәчәк.

– Исегезгә төшерәбез: сораштыру республика буенча уздырыла. Ишегалдының күпфатирлы йортларныкы булуы шарт, – ди Венера Камалова. – Узган ел без Әтнә, Әлки, Теләче, Яңа Чишмә, Тәтеш районнарында эшләдек. Аларда төзекләндерергә тиешле барлык ишегалларында эш тәмамланды.

Иҗтимагый киңлекләр һәм ишегаллары өчен ничек тавыш бирергә соң? Элек «Безнең ишегалды» программасы белгечләре халык белән очрашулар уздырып, алар яшәгән йортларга да киләләр иде. Дөрес, очрашулар әле дә дәвам итә. Әмма онлайн тавыш бирү дә кирәк.

– Моның өчен «Дәүләт хезмәтләре» порталында теркәлергә кирәк. Сораштыру һәр кешенең шәхси битенә җибәрелә. Иң элек иҗтимагый киңлекләр хакында сораулар булачак. Аны үтеп бетергәч, ишегаллары килеп чыга. Үзеңә кирәклесен сайлап, тавыш бирәсең. Бер кеше бары тик бер урын өчен генә үз фикерен калдыра ала. Яшәгән урының матур булсынмы, әллә инде кунакка кайтканымы – анысын сайлыйсың, – ди «Татарстан шәһәрләр үсеше институты» фонды департаментының архитектура проектлары җитәкчесе Наилә Зиннәтуллина. – Республиканың һәр районыннан барлыгы 204 иҗтимагый киңлек катнаша. Казанда – 27, калган районнарда – 3–5 объект. Әлеге исемлектә узган ел эшләре тәмамланып бетмәгән җирләр дә бар.

Илгә карата кертелгән санкцияләр эшкә комачауламый. Венера Камалова әйтүенчә, күп кенә җиһазлар Татарстанда җитештерелә. Парк һәм скверларга куела торган җиһазларны табу буенча кыенлыклар юк, диләр. Наилә Зиннәтуллина, чит ил архитекторлары бездә элеккечә үз эшен дәвам итәчәкләр, диде.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Президент – алтынчы урында

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов төбәк башлыкларының сәяси йогынтысы буенча март ае рейтингында алтынчы урынга чыккан. Рейтингны Сәяси һәм икътисади коммуникацияләр агентлыгы (АПЭК) төзегән. Президент узган айда уртача 7,15 балл җыйган. Аның урыны рейтингнның «Бик көчле йогынты» өлешенә туры килә.

Март ае рейтингына губернаторларның санкцияләргә каршы чаралар эшләүдә катнашуы, инфраструктура һәм инвестиция проектларын тормышка ашыру, урыннарда җәмәгатьчелек белән эшләү һ.б. йогынты ясаган. Рейтинг белгечләр һәм журналистлар арасындагы сораштыру нәтиҗәләре буенча төзелгән. Алар төбәк башлыкларын 1–10 балл буенча бәяләгән.

Балаларга – 63 миллиард сум

Быел төбәкләргә башлангыч сыйныфларда укучыларны кайнар ризык белән тукландыру өчен 63 миллиард сум акча җибәрелә. Хәзерге вакытта чама белән 7,5 миллион бала көненә бер тапкыр бушлай ашатыла. Премьер-министр Михаил Мишустин төбәкләрдә бу хәлне күзәтеп торуның мөһимлегенә басым ясады. Акча бирү мәсьәләсен мәгърифәт министры Сергей Кравцов шәхсән контрольдә тота.

Исегезгә төшерәбез: Россия Президенты Владимир Путин башлангычта укучы барлык балаларны кайнар ризык белән тәэмин итүне йөкләде. Әлеге бурыч 2020 елда Президентның Федераль Җыенга Юлламасында билгеләнде.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Татар телен бушлай өйрәтәләр

Казан федераль университетында татар телен өйрәтү буенча бушлай курслар ачыла. Югары уку йортының матбугат хезмәтеннән хәбәр ителгәнчә, ике айлык курска теләге булган барча кеше язылырга мөмкин. Татарча өйрәнергә теләүчеләргә иң элек телне ни дәрәҗәдә белүен ачыклау өчен тест узарга, онлайн теркәлергә һәм курска кабул итү турында гариза тутырырга кирәк. Гаризаны беренче дәрескә үзең белән алып килү шарт. Шулай ук паспорт күчермәсе таләп ителә.

Курска кабул ителүчеләр исемлеге, дәресләр расписаниесе Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының белдерүләр тактасына урнаштырылачак. Дәресләрне атнага ике тапкыр кичке якта үткәрү күздә тотыла. Бу хакта тулырак мәгълүмат белән танышу өчен 8(843)293-94-52 номерына шалтыратырга мөмкин.

Көнүзәк мәсьәлә

Бер артуның бер кимүе

КЕРТЕМНӘР БУЕНЧА ПРОЦЕНТ СТАВКАЛАРЫ ТӨШӘ БАШЛАГАН

Бу көннәрдә банклар кертемнәр буенча процент ставкаларын төшерә башлаган. Белгечләр моны Үзәк банк төп ставканы 20 процентка кадәр күтәргәч күзәтелгән шаукымның кимүе белән аңлата. Барлы-юклы бер ай вакыт эчендә күпләр кертемнәр буенча югары процентлардан файдаланып калырга өлгергән, банклар да үзләренә билгеле бер күләмдә клиентлар җәлеп итә алган.

Хәтерләсәгез, 1 март көнне Россия Үзәк банкы төп ставканы 20 процентка кадәр арттырып куйды. Бу соңгы еллардагы рекордлы күрсәткеч дип бәяләнде. Моңа кадәр төп ставка 9,5 процент тәшкил итә иде. Үзәк банк мондый адым икътисади чикләүләр аркасында бәяләрнең тотрыклылыгын тәэмин итү, халыкта булган акчаның кыйммәтен саклау өчен кирәк дип аңлатты.

Үзәк банкның көтелмәгән хәбәреннән соң банклар барлык төр кредит һәм кертемнәргә ставкаларны арттырды. Иң беренчеләрдән булып бу үзгәрешне ВТБ банкы эләктереп алды. Баштарак банк, ипотека кредитларын рефинанслау өчен гаризалар кабул итүне туктату турында хәбәр итте, аннары ипотеканың минималь ставкасын 15,3 процентка кадәр күтәреп куйды. Кертем һәм саклык счетларына акчаны исә ВТБда 18 процент ставка белән салырга мөмкин иде. Тора-бара банк аны 21 процентка кадәр үк җиткерде. Әмма бу көннәрдә банк кертем ставкаларын 3 процентка төшерде. Шул рәвешле бүген биредә кертем һәм саклык счетларына акчаны 18 процент ставка белән салырга мөмкин. 1 апрельдән башлап «Почта Банк» та кертем буенча ставкаларны 22 процентган 20 процентка кадәр төшерде. Моңа кадәр 23 процент белән кертем ясарга тәкъдим иткән «Саклык банкы»нда да хәзер акчаны, күп дигәндә, 18 процент ставка белән сакларга мөмкин.

Килеп туган вазгыятьтә берәүләр булган акчасын кайда, ни рәвешле сакларга белмичә аптырганда, ятып калганчы, атып калучылар күбрәк булган. Күпләр банклар кертемнәр буенча югары ставкалар тәкъдим иткәндә, булган акчасын нәкъ менә биредә саклауны өстен күргән. «Открытие» банкы тарафыннан уздырылган соңгы сораштыру нәтиҗәләреннән күренгәнчә, ил халкының яртысыннан артыгы, кертем ставкалары кисәк арткannan соң, булган акчасын банкларга илтеп салган.

Белгечләр моны булган акчаны саклап калуның иң ышанычлы ысулы дип саный.

Хәзерге вазгыятьтә акчаны банкта саклауны дәвам итәргә кирәк. Ник дигәндә, акчаны алсаң да югала. Аны хәзер доллар, еврога алыштырудан мәгънә юк. Банктагы кертемнәрнең 1,4 миллион сумга кадәр өлеше иминиятләштерелгән. Банклар банкротлыкка чыккан очракта да кешегә кертемнәренең әнә шул кадәр өлеше тулысынча түләнәчәк, – ди Казан дәүләт аграр университеты доценты, икътисадчы Илгизәр Гайнетдинов.

КФУның Идарә итү, икътисад һәм финанс институты профессоры Игорь Кох Россиянең банк системасы ышанычлы, кертемчеләрнең сакларга салган акчасын «туңдырырга» бернинди җирлек тә юк дигән фикердә.

– Банклар клиентлары каршында барлык бурычларны үтәргә сәләтле. Үзәк банк аларга бу эштә һәрчак теләктәшлек күрсәтә. Кертемнәрнең билгеле бер өлеше иминиятләштерелгән булу ышанычны тагын да арттыра, – ди белгеч.

Ахыры 2 нче биттә >

Сүзгә-сүз

Вячеслав ВОЛОДИН, Россия Дәүләт Думасы Рәисе:

Ата-аналардан, укытучылардан еш кына хезмәт тәрбиясе мәсьәләсе турында мөрәҗәгатьләр килә. Бу тәрбия мәктәп эскәмиясеннән башлана иде. Бүген бу юк. Рөхсәт тә ителми. «Җыештыручы җыяр», «укытучы тиеш», «балалар укырга гына йөрсен», диләр. Хезмәткә хөрмәтне алай гына тәрбияләп булмый. Ә ул тормышта кирәк. Балаларны иҗтимагый файдалы эшкә җәлеп итү мәсьәләсе турында уйларга тәкъдим итәм.

(«Телеграм» социаль челтәрендәге шәхси сәхифәсеннән)

РОССИЯДӘ – СӘЯХӘТ

Байкал, Алтай, Кырым, Санкт-Петербург. Россиядә яшәүчеләр илнең әнә шул төбәкләрен күрергә хыяллана икән. «SuperJob» хезмәте оештырган сораштыру нәтиҗәләре шул хакта сөйли.

Байкал	24%
Алтай	12%
Камчатка	11%
Кырым һәм Санкт-Петербург	10%
Карелия	7%
Казан	3%

Сөенечле хәбәр!

14 апрельгә кадәр «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» газетасына ташламалы бәядән язылып була!

П2435 жомга саны — Ташламалы бәя **423 сум 48 тиен**, гадәти бәясе – ~~488 сум 10 тиен~~

П2409 атнага дүрт тапкыр чыга — Ташламалы бәя **942 сум 18 тиен**, гадәти бәясе – ~~1099 сум 32 тиен~~

Реклама 16+



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ЯҢА ПАКЕТ ӘЗЕРЛӘГӘНДӘ, ЯКИ ГАРӘПЛӘР БЕЛӘН НИЧЕК КИЛЕШЕРГӘ?

Украина мәйданындагы учак киеренкелекне көннән-көн арттыра. Дөнья илләрендә атом-төш янгыны ихтималлыгына бәйле шик усә. Румыния үз гражданнарына махсус хәрби операциягә бәйле рәвештә йод таблеткалары өләшә башларга җыена. Апрель уртасыннан башлап кырык яшькә кадәрле румыннар аларны бушлай алачак. Атом-төш инциденты булган очракта аларны ничек файдаланырга икәнне дә өйрәтәчәкләр.

Бу юлларны язучы атом-төш сугышы булмас дип өметләнә. Тактик бомба шартлауның бик кечкенә шансы бар барлыгын. Әмма глобаль катастрофа булмас. Планетаның үсеш векторында андый сценарий каралмаган дип беләм. Нәрсә генә булса да, йод эзынлы әйбер түгел инде, аны сәламәтлекне ныгыту өчен профилактик рәвештә болай да кулланырга кирәк. Көнбатыш белән Русиянең икътисади сугышы көчәя. Евросоюз санкцияләренең яңа пакетын әзерли. Анда нефть һәм газ сатуга чикләүләр кертү, Путин даирәсендәгеләргә яңа тыюлар, Россиягә экспортны чикләү, Россия корабларының ЕС портларына керү мөмкинлеген бетерү кебек чаралар каралган. Бүген Евросоюз илчеләре шулар хакында фикер алышу һәм килешү өчен җыела. Беренче чара – углеводородлар сатып алуга эмбарго кертү – иң мөһиме һәм тормышка ашыру өчен иң катлаулысы да. Италия һәм Франция кебек державалар Россия нефтен һәм газын тулысынча диярлек бикләүне куәтли башладылар, чөнки аларның моның өчен мөмкинлекләре бар. Германия, Австрия һәм кайбер башка илләр Себер ягулыгыннан баш тартырга телиләр, әмма булдыра алмыйлар. Кискен рәвештә газдан баш тартса, Германиядә куәтле икътисади тынгырлануы башланачак. Немецлар Россиядән алган газга бик нык бәйле. Газ – җылыту чарасы гына түгел, сәнәгать чималы да бит. Шул сәбәпле Берлин газдан акрынлап баш тартуны уңайрак саный. Алманнарның нефть эшкәртү заводлары да Россия нефтенә көйләнгән.

Углеводород сугышында европалылар Якын Көнчыгыш ярдәменә өметләнә. Әмма СССРны икътисади тынгырлыгуда үзләреннән өлеш керткән гарәп монархияләре аларга колач җәярга ашыкмый. Бу тәбәктә аллә никадәр каршылыклар, үзара кисешеп, чәбәләнеп беткән. Гарәпләр, бердән, АКШның Иран белән атом-төш килешүе тозүенә риза түгел. Берләшкән Гарәп Әмирлекләре Вашингтонның мәшһүр F-35 хәрби очкычын үзләренә сатуны суздына канәгатьсезлек белдерә. Согуд Корольлеге Йәмән гыйсъянчыларына каршы хәрби ярдәм күрсәтүне таләп итә. Ике дәүләт тә Ак йорт белән иминлек гарантияли торган зур килешү төзергә тели. Әмма гарәпләр таләп иткән килешүне төзү өчен, Америка Сенатының өчтән ике өлеше аны якларга тиеш. Байденның Сенатта ул кадәр үк йогынтысы юк. АКШ лидерының, корольне нефть сатуны арттырырга үгетләргә дип, Әр-Риядка барырга теләвен, әмма очрашуны килешүгү өчен телефон сөйләшүләренә ирешә алмавын яза дөнья матбугаты. Согудлар Вашингтонның үзләрен Patriot зенит-ракета комплексыннан мәхрүм итүенә дә бик ачулы, ахрысы. Бу хатасын АКШ төзәтә инде. Март урталарында күп Patriot гарәп чуленә китерелде, диләр.

Россиядә

КАЙТСЫННАР ДА ЭШЛИ БАШЛАСЫННАР

Россиянең әчке проблемалары да махсус хәрби операциягә бәйле рәвештә кертелгән санкцияләр тирәсендә үсә. Көн саен диярлек чит ил компанияләре илне ташлап китә. Соңгы көннәрдә генә ExxonMobil дигән Америка компаниясе «Сахалин-1» сыек газ җитештерү проектыннан чыгу турында белдерү ясады. Алар үзләренең бу адымнары нәтиҗәсендә 4 миллиард доллар акча югалтуларын таныйлар, әмма барыбер проектны «тундыра»лар. Болар «Макдоналдс» һәм «Икеа» гына түгел, үзләре белән технологияләрне дә, күп вакытта югары квалификацияле белгечләрне дә алып китә. Чит илләргә бәйлелекнең масштаблары ачыклана һәм таң калдыра. Безгә товар тәргәкли торган материалларны да, хәтта йомырка тутыра торган савытларны да чит ил компанияләре җитештереп биргән икән. «Российская газета» 2021 елда целлюлоза катырсысы белән Россияне 73 процентка европалылар, 12 процентка азиатлар тәэмин иткән, калган 15 процентны гына үзебездә җитештерүебезне әйтә. Катырсы җитештерүче «Кама» целлюлоза-катырсы комбинатына базар ачыла инде ачылуын, әмма куәте җитмәстер, мөгаен. Комплектлаучы детальләр, югары технологияләр таләп итүче микрочиплар җитештерүне җайга салу кирәк булачак. Боларны тормышка ашыру исә бик авыр. Инвестицияләр кирәк, технологияләр сорала, белгечләр табасы бар. Әле үзебезнең продуктларын да күбесе чит ил җиһазларында җитештерелә.

Күп тармакларны нульдән торгызырга туры килачәк, моның өчен белгечләр кирәк. Югары квалификацияле чит ил белгечләренә масштаблы бонуслар игълан ителсә дә, Россиягә инженер-техник белгечләр ил булган мөһаҗирләр агыла башлар дип өметләнергә ярамый. Кайчандыр Россиядән китеп, чит илдә төпләнгән кадрлар үзләрен яңа шартларда үңайлысы тоя икән. Менә шулар соңгы вакытларда ил җитәкчелегенә ватанга кайтуда ярдәм сорап мөрәҗәгать итә башлаган. Бу хакта «Известия» газетасы яза. Бу фейк түгел, Россия министрлыклары югары квалификацияле белгечләрне илгә кайтару программасын эшли башлаган инде. Сүз Россиядән китүчеләр генә түгел, рус телле булу сәбәпле ватандаш дип табылган барлык кешеләр турында да бара. Андый ватандашларны кайтару программасы элек тә бар иде. Хәзер кыйммәтле профессия ияләрен илгә кайтару өчен яңа махсус проект тормышка ашырылырга әзерләнә. Моңарчы Россиягә Казахстан, Таҗикстан кебек илләрдән кайтып төпләнгәннәр. Яңа шартларда Европа илләрендә яшәүчеләр тарихи ватанга сагына башлаган, чөнки тегендә аларга басым арткан. Аңлашыла инде: яңа ватандашлар югары хезмәт хакы һәм уңайлы яшәү шартларны таләп итәчәк. Вак-төяк компенсация һәм «подъемный» акчаларына гына риза булмаслар. Берничә министрлык кабинетларында бүген шуларны кызыктырырлык шартлар тудыру программасы эшләнә. Шунысы кызык: проектны Әчке эшләр министрлыгы әйдәп алып барачак икән.

Аңлашу үрнәге

Аңлашу һәм җаваплылыктан курыкмау. Татарстанның ЮНЕСКО кебек абруйлы халыкара оешма белән күпьеллык хезмәттәшлеге нигезендә беренче чиратта шул сыйфатлар ятадыр.

Республика ЮНЕСКО белән ныклап торып якынаюны 1983 елда башлый. Ул елны, туууына 800 ел тулу уңаеннан, Кол Гали исемен ЮНЕСКОның истәлекле көннәр календарена кертәләр. Соңрак бу исемлектә Габдулла Тукай да урын ала. 2000 елда исә Казан Кремле комплексы ЮНЕСКО Бөтендөнья мирасы исемлегенә кертелә. Бер елдан соң республиканың рәсми делегациясе ЮНЕСКО штаб-фатирына барып, Татарстан һәм оешма арасындагы хезмәттәшлек турындагы беркетмәне имзалыйлар. Документ нигезендә, Татарстан «ЮНЕСКО – дөнья төбәкләре» кысасында эш итүче беренче дәүләт булып таныла. Билгеле, бу вакыйгаларда республиканың беренче Президенты Минтимер Шәймиев шәхесе, башлап йөрүе дә әһәмиятко ия. Хәзер исә ЮНЕСКО саклавындагы корылмалар өчәү: Кремльдән тыш, Зөя утрау-шәһәрчеге белән «Болгар» музей-тыюлыгы да дөнькүләм әһәмияттәге корылмалар исемлегенә кертелде.

Күркәм эшләр әле дә дәвам итә. Казанны ЮНЕСКО комитетының 45 нче сессиясен уздыру урыны итеп сайлаулары да җаваплылык һәм ышаныч, озак еллар нәтиҗәле эшләүнең җимеше булмый ни булсын?! Бу очрашу әле тагын да күбрәк башлангычларга юл ачар. Дөнья күләмендә бу җәһәттән «Татарстан моделе» дигән аты бар инде республиканың.

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановның ЮНЕСКО эшләре буенча комиссиясе җаваплы сәркатибе Григорий Орджоникидзе белән кичәге очрашуы да матур гамәлләрнең дәвамы, яңа уртак проектлар турында сөйләшүгә бәйле булды. Республика Президенты аңа күпьеллык нәтиҗәле хезмәттәшлеге һәм төбәктә тарихи мирас объектларын булдыруга керткән өлеше өчен «Татарстан алдындагы казанышлар өчен» ордены медален тапшырды. Очрашуда республиканың Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев катнашты.

Сүз уңаеннан, Григорий Орджоникидзе Казанга эш сәфәре белән килде. Ул ЮНЕСКО Бөтендөнья мирасы комитетының 45 нче сессиясен уздыруга әзерлек мәсьәләләре буенча киңәшмәдә, шулай ук Россиядә ЮНЕСКО кафедраларының координацион комитеты утырышында катнашачак.

tatarstan.ru

ХУҖАСЫЗЛЫК ЭШТӘН ЧЫГАРА

Татарстан буенча Росреестр идарәсе мәгълүматларыннан күренгәнчә, республикабыз территориясендә ниндидер сәбәпләр белән хуҗасыз калган объектлар шактый күп. Сүз дә юк, андый корылмаларның ни хәлдә ятканын һәркем чамалыйдыр. Шуңа күрә дә Росреестр идарәсе мондый «байлык»ның милекчеләрен эзләү белән мәшгуль.

Соңгы 9 ай эчендә генә дә 6,1 мең объектның хуҗасы ачыкланган, 6,5 меңе кадастр исәбеннән төшерелгән. Әлек исәптә булган объектларның хокуклы хуҗаларын ачыклауны тәртипкә салу 2021 елның 29 июнендә кабул ителгән федераль законда каралган.

– Татарстанда барлыгы 700 меңгә якын корылма турында бернинди мәгълүмат та юк, – ди идарә җитәкчесе урынбасары Лилия Борһанова бу җәһәттән. – Аларны тәртипкә китерүнең нинди файдалы яклары бар соң? Теркәлгән очракта реестрга хуҗа кешенең контактлары да языла. Димәк, алар белән теләсә кайсы вакытта элемтәгә керәп булыр иде. Бу исә аларны төрле мошенниклардан якларга мөмкинлек тудыра. Әгәр хуҗалар исә үз милке белән ничек телиләр, шулай идарә итә алалар дигән сүз.

Росреестр идарәсе хәбәр иткәнчә, теркәлгәннән соң хуҗа кеше электрон почта аша милкенә кагылышлы теләсә нинди үзгәреш турында мәгълүмат алып торачак. Күршеләр белән җир чикләре буенча аңлашылмаучылыклар килеп чыкса да, аны хәл итәр өчен идарә тәкъдимнәр кертәчәк. Димәк, дошманлашуга кадәр җиткергән бәхәсләрнең булмый калуы да бар. Әгәр милек дәүләт ихтыяҗы өчен кулланылса (мәсәлән, юллар, төрле учреждениеләр төзегәндә) – компенсация, табигать фаҗигаләре (янгын, су басулар) булса, иминият түләүләре билгеләнәчәк.

Бу шене сузып йөрүнең бернинди мәгънәсе дә юк. Милек теркәлмәгән очракта, иртәме-соңмы, закон нигезендә объект барыбер кадастр исәбеннән төшереләчәк.

Элек исәпкә алынган милекне ничек теркәргә?

Мондый объектларның хуҗаларын ачыклау вәкаләтләре дәүләт власте һәм җирле үзидарә органнарына бирелгән. Закон кысасында муниципалитетлар архивларындагы документларга мөстәкыйль төстә анализ ясыйлар, салым, эчке эшләр органнарыннан, Пенсия фондларыннан, ЗАГСлардан, нотариуслардан мәгълүматлар соратып алалар. Әгәр объектның хуҗасы ачыкланса, Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрына кертер өчен, барлык мәгълүматны Росреестрның Татарстан идарәсенә җибәрәләр.

kzn.ru

Милек хуҗасына ни дә булса эшләргә кирәкмe?

Бу очракта милек хуҗасыннан берни дә таләп ителми. Әмма милекчеләр үз хокукларын мөстәкыйль төстә терки алалар. Моның өчен мәгълүматларны реестрга теркәүне сорап гариза язарга һәм, объект турында булган документларны да теркәп, күпфункцияле үзәккә мөрәҗәгать итәргә кирәк.

2021 елның 1 гыйнварыннан мондый объектларны теркәү өчен дәүләт пошлинасы алынмый.

Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрында теркәлгәнме-юкмы икәнен ничек белергә?

Бу сорауны Росреестр порталы ярдәме белән милек хуҗалары үзләре дә ачыклый ала. Моның өчен Росреестр сайтында «Онлайн режимда күчемсез объектлар буенча белешмәләр» электрон хезмәтенә мөрәҗәгать итү дә җитә.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

Бер артуның бер кимүе

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

– Банкларга кертемнәр буенча процентларның түбән булуы отышлы, билгеле. Әмма алар да үзара көндәшлек итә, клиентлар өчен көрәшә. Шуңа күрә, телиме-теләмиме, башкаларга ияреп, банклар да процент ставкаларын арттырырга мәҗбүр. Аларның процент ставкаларын бер-бер артлы күтәреп, төшереп уйнавы, нигездә, әнә шуның белән аңлатыла.

Икътисад тармагында кайнаган белгечләрнең күбесе кертемнәр буенча процент ставкалары алга таба да төшәчәк, дип фаразлый. Башкаладагы аналитик үзәк җитәкчесе Василий Карпунин фикеренчә, якын арада Үзәк банк та төп ставканы төшерергә мөмкин.

– Кертемнәр буенча процент ставкалары алга таба да кимүен дәвам итәчәк. Март башында Үзәк банкның төп ставканы арттырып куюы аркасында пәйда булган шаукым тынды. Кеше югары процентлардан файдаланып, булган акчасын кире банкларга илтеп салды. Вазгыять тотрыкланды. Шуңа күрә банкларга депозитлар өчен югары процент тәкъдим итүдән мәгънә юк. Миңа калса, киләсе утырышта Үзәк банк та төп ставканы төшерер, – дип фаразлый белгеч.

Кертем буенча ставкалар төшсә дә, ипотека процентлары элеккечә үк югары кала бирә. Шул ук март башындагы шаукымнан соң алар да икеләтә диярлек артты. Бүген ипотека кредитын 20 проценттан да түбәнрәк ставка белән рәсмиләштерәм димә. Шул сәбәпле, соңгы ике атна эчендә Россиядә рәсмиләштерелгән ипотека килешүләре 5 тапкыр (!) кимегән. Белгечләр моны санкцияләр аркасында кайбер оешмаларның ябылуы сәбәпле, күпләрнең эшсез калуы белән дә бәйләп аңлата. Ипотека алырга азмы-күпме мөмкинлеге булган кешегә дә бераз сабыр итәргә куша алар. Ник дигәндә, Үзәк банк төп ставканы төшереп, ипотека ставкалары да бераз төшмәсме дип өметләнә алар.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

«ИКЕНЧЕ ИКМӘК» КАДЕРЕ АРТЫРМЫ?

Авыл сулышы

Гомер буе «икенче икмәк» дип йөртелгән бәрәңгегә авыл халкының да мөнәсәбәте үзгәрү турында берничә тапкыр яздык инде. Бүгенге кебек он-ярма, башка төр ризыкларга бәяләр нык арткач, күпләр аларның фикере үзгәрер дип көтә. Моңа кадәр һаман бәрәңге генә ашап яшәмәбез дигән саланыклар бүгенге вазгыять шартларында ни уйлый соң? Бәрәңге басуларын элекке кебек арттырырлармы? Терлек азыгы бәяләре, бигрәк тә мал оны, ашлык бәяләре котырып үскән мәлдә, бәрәңге – мал-туарга да бер дигән азык бит әле.

– Быел гына бөтен кеше дә бәрәңге утыртуга күчәр дип уйламыйм, – ди күрше авылда яшәүче танышым Наил абый. – Читтәге басуларны гына түгел, яндагыларын да киметеп, печән үстерә башлаган идек бит. Печән җиренә әйләнгән басуларны бәрәңге утыртырлык хәлгә китерү өчен, бик күп көч, тырышлык кирәк. Башта печән басуын кистергечләр белән вакылап, кистертеп чыгарга, аннан сукалатырга, культивация ясарга, печән тамырларын җыйнап бетергәнче тырмаларга, кыскасы, хәйран гына тир түгәргә кирәк. Аларның берсен дә техникадан башка эшләп булмый. Чыгымнарын әйтәсе дә юк, әнә шул кадәр тракторчының җаен туры китерәсе бар. Яз көне эшләре болай да тыгыз, бу эшләрне дә чиратка куеп булмый, бәрәңге утырту өчен уңай вакытка өлгертергә кирәк. Әле көздән кистереп, сукалатып калганда да тамакта туры килә. Өстәвенә печәнлөн җирнең бөтен «аш»ын, уңдырышлылыгын алып бетергән була, аны әйбәтләп ашларга да кирәк. Бу кадәренә ниятләгән кешегә да быел утырту өчен орлыклык бәрәңге табу – үзе проблема, баясе дә шактый кыйммәт. Киләсе елларга арттырырлармы, дисеңме? Анысын да белеп булмый. Ни дисәң дә, бәрәңге үстерү соңгы елларда бик чыгымлыга әйләнде һәм бик нәзберек культура да бит. Нинди генә авырулары юк. Ничә тапкыр агу сибәргә, чүбен утарга, төбен ердырырга кирәк... Әле тагын нава торышы нинди килә. Анысы да бик мөһим.

– Мин дә быел гына бөтен кеше бәрәңге басуларын зурайтыр дип уйламыйм, – ди Нөнәгәрдән танылган бәрәңге үстерүче Нотфулла абый Гарипов. – Былки киләсе елларда акрынлап арттырырлар. Быелга утырту бәрәңгесе табу кыенрак. Үткән ел күп кешедә аз гына участогына утыртырга җитәрлек тә бәрәңге булмады бит. Сүз уңаеннан, мондый кешеләргә киңәшем: бәрәңгене ярып утыртудан курыкмасыннар, бер күздән дә үсә ул. Без үзебез 40 сутыйга бәрәңге утыртабыз. Бик күп төрле сортлар белән эшлим. Бәрәңгенең яңа сортларын бер күздән үрчетәм. Элек шәхси хуҗалыклар бәрәңге сату белән бик мавыкмады, үзеннән артканын малга ашатты. Ә колхозларныкын басудан ук төяп алып китеп бардылар. Алар да сату белән проблема күрмәде. Соңгы елларда ашлык-оннарга кытлык булмады, шәхси хуҗалыклар, шул сәбәпле, бәрәңге үстерү мәшәкатьтеннән читләште. Ә күмәк хуҗалыкларны бәрәңгегә сорау булмау, бәясе түбән булу һәм башка күптөрле сәбәпләр биздерде дип беләм. Быел әнә бәрәңгегә сорау зур булды, районнардагы хуҗалыклар үзләре үстермәгән, ашханәләренә дип алып киттеләр. Казан, Биектаудан да сораучылар булды. Башка елларда күбесенчә Нократ Аланы базарында сатта идек. Быел утырту бәрәңгесе дә күп калмады инде...

– Район җитәкчеләреннән күмәк хуҗалыкларга бәрәңге утыртырга фарман булмады. Хәзер инде һәр хуҗалык нәрсәне күбрәк үстерәсен үзе хәл итә. Бүген бит бәрәңгене элеккечә итеп кенә үстереп та булмый. Махсус техникалар комплексы кирәк. Бездә инде алар фәкать «Татарстан» хуҗалыгында гына калды, – ди Балтач районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы Фирдәвес Нәбиуллин. – Ә менә дәүләт субсидия белән кызыксындырса, шәхси хуҗалыклар кабат күп итеп бәрәңге үстерә башлар дип уйлыйм. Бер чорда сыерлар кимегәч, нәкъ менә хөкүмәт биргән ярдәмнең файдасы булды, кешеләр сыерларны арттырды. Шөкер, бездә аларны әле дә киметмәделәр. Бәрәңгегә килгәндә, районда аны күпләп үстерүчеләр, бу эш белән шөгыльләнүче фермерлар юк.

– Кыш буе бәрәңге сатып чыктык, – ди районда бердәнбер бәрәңге үстерүче «Татарстан» хуҗалыгы (тагын бер хуҗалык үз ихтыяҗларына 5 гектарда гына үстергән) баш икътисадчысы Шамил Гомәров. – Алдагы елда 100 гектарда үстергән идек. Һәр гектардан уртача 446 центнер уңыш алдык. Сату бәяләре дә торышка күрә ярыйсы булды. Бәрәңге сатудан 6 миллион 882 мең сум акча керде. Ә 2021 елда 80 гектарда үстердек. Корылык ел булса да, сугарулар, яфрактан туклындырулар, башка күрелгән чараларның ярдәме булды – бер гектардан 288 центнер уңыш алынды. 9 миллион 600 мең сумга якын табыш алдык. Бүген дә сатабыз. Көздән үк инде эре бәрәңгенең килограммы 20–25 сум булды. Соңгы вакытта эресен – 40, утырту бәрәңгесен 15–20, малга ашата торганын 8 сумнан сатабыз. Барысын да алалар. Язга таба сораучылар тагын да артты. Үзебезнең районнан гына түгел, читләрдән дә килаләр. Бәрәңге әйбәт саклаган, зур саклагычыбыз бар. Быел кабат 100 гектар утыртырга ниятлибез.

Нотфулла Гариповның шәхси архивыннан

Билгеле, мондый бәяләр, мондый ихтыяҗ булганда бәрәңге дә рентабельлегә әйләнә шул. «Икенче икмәк» дисәң дә урынлы буласы...

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

Бәйге

УНИКЕ БУЫНГА ҖИТКӘН ШӘҖӘРӘ

Иске Суыксу авылында яшәүче Равил Шәрәфетдинов оныкларына бик зур байлык калдыра – кәгазьгә төшерелгән һәм электрон версиядә ясалган шәҗәрә. Анда 1610 елдан башлап әби-бабайлар һәм туганнар кертелгән.

Пенсиядәге укытучы үз гомерендә барлыгы дүрт шәҗәрә ясый – әтисе һәм әнисе ягыннан әби-бабаларыныкын. Иң озыны – 12 буынлысы әнисенеке әтисе Сабирҗан абыйныкы. Ул 1610 елдан башланган буыннар турындагы мәгълүматларны сары кәгазьдән ясалган дәфтәргә язып калдырган. Махсус белеме булмаса да, үзенең зыялылыгы белән яшьтәшләреннән аерылып торган Сабирҗан бабай архивларда казынып, туганнарыннан, чордашларыннан сорашып, күбесенең исем-фамилияләрен, туган һәм вафат булган елларын да белә алган. Ул аларны язу карасы белән теркәп калдырган. Шәҗәрәне үзе вафат булганчы, 1961 елга кадәр язган.

Оныгы Равил Шәрәфетдинов әйтүенчә, буын тарихы Төмән өлкәсеннән күченеп кайткан Моратбакый һәм Авазбакый бабайдан башлана. Аларның кече сеңелләре дә булган, тик аны Буа районына күченеп кайтканда кияүгә биреп калдырганнар. Әлеге ике бабай Иске Суыксуга Буадан килүче төп юл кергән торган урамда гомер кичергәннәр. Сабирҗан бабай ягыннан туганнар әле дә шунда яши, ди Равил абый.

– Бу – үзе бер тарихи факт. Элек бәхетне читтән эзләмәгәннәр. Ир бала үсеп җитеп, гаилә коргач, күршедә буш җир участогы яки йорт бар икән, шунда күченгән. Ә кыз балаларның күбесе авыл егетенә кияүгә чыккан, – ди ул бу хакта.

Дәфтәрне Равил абыйның әнисе Тәнзилә апа саклаган. Ул үләр алдыннан әтисе Сабирҗанның шушы истәлеген улына тапшырып калдырган. Үзе белгән туганнарны өстәп язудан да булган.

Равил абый шәҗәрәне тулыландыруга чын-чынлап керешә. Күп мәгълүматларны авыл җирлеге архивында сакланып калган хуҗалык китапларыннан эзләп таба. Нәселдәге һәрбер фамилияне иң кадерле истәлек итеп дәфтәренә теркәп бара. Шулай итеп, Равил абыйның дәфтәре көннән-көн тулылана.

– Әни әтисе шәҗәрәсен тикмәгә генә биреп калдырмады. Мин моны аңа бер билге, аманәт итеп кабул иттем. Хәзерге акылым белән тагын да күбрәк аңлыйм: бу – зур байлык. 12 буын шәҗәрәсен төзү районда гына түгел, республикада да бик аз кешегә генә насыйп булгандыр, – ди ул.

Компьютер сатып алгач, аның электрон версиясен дә ясау теләге туа.

ВТ Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгына багышлана

БЕЗНЕҢ АВЫЛ ИМАМЫ

– Улым Рөстәм белән графикалау программасын кулланып, дәфтәрдәге һәрбер мәгълүматны югалтмыйча, компьютерга керттек. Күрәсезме, тармаклап киткән исем-фамилия язылган шакмаклар төрле төстә. Без шулай һәрбер буынны аерым төс белән билгеләдек, – ди ул, безгә экрандагы шәҗәрәләрне күрсәтеп.

Аның әйтүенчә, болай эшләү күпкә отышлы: дәфтәр югалырга мөмкин, ә монысын компьютер хәтерендә яхшы итеп сакласаң, беркайчан да югалмаячак. Аннары оныклар да хәзер электрон версияле мәгълүматка ияләшкән. Компьютердагы шәҗәрә барлыгы 53 биттән тора. Әле тагын тулыландырасы бар, ди.

– Хыялым бар: электрон форматта шәҗәрәне агач формасында ясап, бер биткә туплау. Улым Рөстәм: «Моны эшләп була, махсус программа бар», – ди. Күз алдына китерегез: агачның «Рузинә һәм Равил Шәрәфетдиновлар» дигән яфрагына басасың, анда минем балаларым, оныкларым хакындагы мәгълүмат килеп чыга. Уңайлы бит, һәрбер яфрак үз буыны хакында хәбәр итә. Бер нәселнең дүрт гасырлык тарихы бит бу, – ди шәҗәрә авторы.

Тарих дигәннән, ул районыбызда иң борынгы мәчетнең имамы вазыйфасын да башкара. Иске Суыксу авылында аны беренче номерлы, дип йөртәләр. Әлеге борынгы корылманың тарихы белән күптән кызыксынган. Аның әйтүенчә, борынгы Казан шәһәрендәге Зәңгәр мәчетнең элеккеге бинасы булган. Кем икәнен төгәл белми, бәлки шушы авылдан чыккан кешедер, аны бирегә алып кайтып урнаштырган, ә Казанның Зәңгәр мәчетен яңадан төзегәннәр. Алдан бина, билгесез сәбәпләр аркасында, юл уртасына урнаштырылган булган, соңрак аны хәзерге урынга күчергәннәр.

Равил абый мәчет тарихын балаларына, оныкларына гына түгел, мәхәлләгә йөрүчеләргә дә сөйли. Алар да, имамга кушылып, борынгы бинаның җимерелүенә юл куймаска тырышалар. Сер түгел, мәчетне күп еллар буе ремонтларга туры килгән.

– Киләчәктә Зәңгәр мәчетнең элеккеге бинасы хакында күбрәк беләсем килә. Бәлки Казандагы архивта аның хакында мәгълүматлар саклангандыр. 12 буынлы шәҗәрәм үземнән соң нәселемә мирас булып калса, ә мәчет бинасының тарихы авыл өчен кадерле истәлек булыр иде, – ди имам.

Әлфинур ЙОСЫПОВА

1100 еллык тарих

Хөрмәтле укучыларыбыз! Тарих фәннәре докторы, профессор Фаяз Хуҗин ярдәме белән без 1100 ел элек Идел Болгарстанында ислам дине кабул ителү уңаеннан тарихи язмалар циклын башлыйбыз. Болгарда озак еллар казу эшләрен алып барган, ислам дине тарихын өйрәнүгә зур көч куйган галимгә шушы уңайдан сорауларыгызны да җиткерә аласыз.

Болгар яңарыш кичерә

922 елның 21 маенда (иске стиль буенча 16 майда) Россиядә яшәүче хәзерге заман татарларының болгар бабалары, ислам динен рәсми рәвештә Болгар шәһәрендә кабул итеп, мөселман дөньясының бер өлешенә әверелде.

Шушы тарихи вакыйгага кадәр Идел буе болгарларына, әле ул чакта ярым күчмә кабиләләргә, аларның көньяктан күченеп килеп, утрак тормышка күчүе, төбәкнең яңа табигый-географик һәм климат шартларына җайлашуы, Идел-Кама буйларында яшәп ятучы җирле халыклар арасында сәяси гегемон буларак формалашуына бәйле шактый катлаулы һәм озын бер этап үтәргә туры килә.

Төрки телле һәм җирле фин-угор кавемнәрен үз эченә алган Болгар җәмгыяте яңа идеологиягә мохтаҗ була, чөнки күп аллалыкка нигезләнгән мәҗүсилек илтабар Алмыш һәм аның тирәсендәге югары катлау вәкилләренең төрле кабиләләрне берләштерү юлы белән куәтле дәүләт төзү планнарын тормышка ашыруга киртә булып тора. Бу максатка шул заманнарда таралган монотеистик, ягъни бер Аллага таянучы диннәрнең берсе генә идеология коралы булып хезмәт итә ала. Мондый идеология сыйфатында, Болгар хакиме Алмыш оешып килә торган дәүләтнең төрле кавемнәрен бердәм халыкка тупларга сәләтле ислам динен сайлап ала.

Бу дин болгарларга күптән таныш булган. Аларның бер өлеше әле Хәзәр каһанлыгында яшәгән чорда ук мәҗүсилектән, дөресрәге, тәңречелектән мөселман dиненә күчкән була. Биредә Шәрыкнең иң зур Ислам мәдәнияте үзәге – Хәрәземнән килгән мөселманнар күп була. Болгарның Урта Азия белән сәүдә һәм мәдәни элемтәләре Иделдә дәүләт барлыкка килгәнче үк урнашкан. Бу элемтәләр тугандаш төрки халыклар арасында рухи бердәмлекне ныгытуда сизелерлек роль уйнаган.

Шилки углы Алмыш хан Урта Азиядә таралган хәнәфи мәзһәбенең сөнни исламын әле IX гасыр ахырында ук кабул иткәндер дип фаразлана. 902–908 елларда сугылган болгар тәңкәләрендә аның мөселман исеме Җәгъфәр ибн-Абдаллаһ дип күрсәтелгән. 922 елның 21 маенда исә Идел Болгары ерак Багдадтан чакырылган дәрәҗәле кунаклар тарафыннан рәсми рәвештә мөселман дәүләте дип таныла һәм аның ислам цивилизациясе дәүләтләре составына керүе уңаеннан тантаналар уздырыла.

Әлеге истәлекле тарихи вакыйгадан соң 1100 ел узды.

Татарларның болгар бабалары белән бәйләнгән бар нәрсәгә карата дулкынландыргыч мөнәсәбәтен аңлау кыен түгел. 2010 елның октябрендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Болгарда ислам динен рәсми кабул итү көнен истәлекле дата дип игълан итте, һәм ел саен мөселманнар бу көнне зур бәйрәм буларак билгеләп үтәләр.

Хәтта республикадан читтә яшәүче татарлар да Болгарның изге урыннарына сәяхәт кылуны үзләренең изге бурычлары дип саныйлар, борынгы легендаларны, риваятьләрне хәтерләрендә саклыйлар. Дистәләрчә күренекле фән һәм мәдәният эшлеклеләре, XIX гасырга кадәр «Болгари» тәхәллүсен үз исемнәренә һәм фамилияләренә кушып, зур горурлык хисләре кичергәннәр. Соңгы елларда исә Казанда һәм Ульянда – болгар шагыйре Кол Галигә, Алабугада Ибраһим ханга скульптура һәйкәлләре ачылды.

Алтын Урда дәүләтчелеге чорында чәчәк атып яшәгән Болгар шәһәре, хәтта җимерелеп юкка чыкканнан соң да, кызыксынучан сәяхәтчеләрне үзенә җәлеп итеп торудан туктамаган. Аның хәрабәләрен зиярәт кылырга югары дәрәҗәле дәүләт җитәкчеләре, императорлар Петр I һәм Екатерина II, атаклы дин әһелләре, дөньякүләм танылган зур галимнәр килеп киткәннәр.

Бүгенге Болгар чын-чынлап «Яңарыш чоры» кичерә. Республикабызның беренче Президенты Минтимер Шәймиев башлангычы белән оешкан «Татарстан Республикасы тарих һәм мәдәният һәйкәлләрен торгызу фонды»ның актив эшчәнлеге һәм хөкүмәтебез тарафыннан кабул ителгән «Татарстан Республикасы мәдәни мирасы: борынгы Болгар шәһәре һәм Зөя утрау-шәһәрчеге» комплекслы программасын тормышка ашыру нәтиҗәсендә шәһәрлекнең масштаблы археологик тикшеренүләре, яңа ачык архитектура корылмаларын консервацияләү һәм реставрацияләү, шәһәрлек территориясен төзекләндерү эшләре алып барылды. Яңа музейлар ачылды. Алар арасында уникаль Болгар цивилизациясе музее да бар. Ак мәчет һәм янәшә урнашкан Ислам академиясе ачылу Болгарны яңадан Ислам цивилизациясе үзәгенә әйләндерде.

Болгарга бүген дә халык ташкыны агыла. Россиянең төрле төбәкләреннән һәм чит илләрдән килгән туристлар Идел буе болгарларының, аларның турыдан-туры варислары булган татар халкының борынгы һәм заманча мәдәнияте белән танышудан чын ләззәт алып китәләр.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА әзерләде

(Дәвамы бар)

Тормыш кыйпылчыклары

«Кулларың да олыгайган икән...»

Бер көн, йомыш төшеп, район үзәгендәге бер оешмада эшләүче танышым янына барган идем. Минем арттан ук диярлек аның элекке авылдашы килеп керде. Ишектән үк шау-гөр килеп керде, балкып исәнләште дә, бөтен игътибарын миңа төбәп: «Нишләп утырасың монда?» – диде бу, бик якын итеп. Күңелемнән нинди танышым икән дип уйлана-уйлана: «Килдем әле менә», – дидем. Шул арада ул ялгышканын аңлап: «Әй, мин сине үзебезнең авылдашка охшаттым бит, куллары да олыгайган дип уйладым әле», – ди бу. Аның соравы гади генә иде, ничек керсә, шулай чыгып та китте. Мин исә, ирексездән, тамырлары бүрткән кулыма, ничә тапкыр кысылып, имгәнеп, шешмәкләнеп калган буыннарыма карап: «Әле ярый битлек бар иде, җыерчыкларың да күбәйгән икән, дип тә әйткән булыр иде», – дип көлемсерәдем. Юк, җыерчыкларымнан да, олыгайган кулларымнан да оялмыйм анысы. Турыдан бәреп әйтергә күнеккән ул ханымга да үпкәләмәдем. Эчкерсезлек галәмәтедер, дидем. Минем якка бер күз ташлау белән кулларымны күрергә, бәя бирергә өлгергәненә сокландым да бугай әле...

Бу – гомерлек дус, монысы...

Без яшүсмер чакта күбрәк Гражданнар сугышы, колхозлашу чоры, Бөек Ватан сугышы турында әдәби әсәрләр укып үстек. Шуларны укыгач, мин гел: «Бигрәк кызыксыз чорда яшибез», – дип уйлый идем. Геройларның тормышы маҗаралы, ыгы-зыгылы итеп тасвирлана иде шул. Бүген инде берничә дистә ел үткәч, безнең буын кешеләре дә шактый матавыклы, сикәлтәле чорларны үткән, уйлап карасаң, без дә бит бик күп тарихи вакыйгаларның шаһиты булганбыз икән дия торган. Ул елларда мин



«Дорога домой» хәйрия фонды архивыннан

сабыйлыгым белән: «Ничек инде кемнең – аклар, кемнең кызыллар ягында булуын белмиләр? Монысы – дус, монысы – дошман икәне ярылып ята бит», – дип тә уйлана идем. Тормыш исә моның бик катлаулы булуын, кемнең – гомерлек дус, кемнең беренче борылышка кадәр генә синең янда булуын аңлар өчен зирәклек-зиһен дә, еллар да түгел, ачы чынбарлык кирәклегенә, кайчакта кечкенә генә бер очрак та җитеп ашасына төшендерде кебек...

Биш икән биш

Бу көннәрдә кибетләрдә социаль яктан әһәмиятле товарларны санап кына бирә башладылар. Район үзәгендәге кибетләр челтәренә кергәч, гадәт буенча, кечкенә пакеттагы «вискас»ны күбрәк алган идем, кассир кыз иплә кенә: «Апа, безгә бер төрле товарны бер кулга биштән артык бирмәскә куштылар», – дип, калганнарын алып калды. Биш икән биш, мин әйтәм. Икенче баруымда тагын бишне алдым. «Менә син дә әһәмиятле җан иясенә әйләндең, – дим Казаннан безгә күченгән, әлегә шул «вискас»тан башка нәрсә ашамаган песигә. – Болай булса, лапастагы иптәшләрең күк сөткә, авыл ризыгыңа күчмәгәең...» Әлегә бирешергә җыенмый, күрәсең, бу статусы песигә күбрәк ошый...

Үзенә дә юк, безгә дә

Эш белән баргач, бер авылда күренекле авылдашлары, алардан булган ярдәмнәр турында сөйләшә киттек. Бу авылдан алар шактый чыккан, күп еллардан бирле ярдәм итеп, туган нигезләрен генә түгел, авылны саклау, яшәтү өчен дә тырышалар икән. Сүз үз һөнәре буенча республикада мактлып, үз тырышлыгы белән күтәрелгән уртак танышыбызга җиткәч, әңгәмәдәшебез: «Әй, аннан үзенә дә юк, безгә дә юк», – дип көлеп җибәрде. Зарланып әйтми ул аны, әлеге танышыбызның гаделлеген, принципиальлеген икебез дә беләбез. Намус белән, тырыш, гадел хезмәт белән яшәргә күнеккән кеше, нинди биеклекләргә күтәрелсә дә, теләгәндә шундый булып кала ала икән дип уйладым мин. Аның йөз аклыгы – авылдашлары өчен дә мәртәбә, шул ягы белән мең ярдәмнән кыйммәт тоелды миңа.

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

КОТЛЫЙБЫЗ!

Республикада физик культура һәм спортны үстерүгә зур өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Батыр» олимпия резервы республика спорт мәктәбе» дәүләт автоном учреждениесе тренеры **Антонова** Елена Петровна; күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм республиканың сәнәгать комплексын үстерүгә зур өлеш кертүе өчен «Оргнефтехим-Холдинг» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры **Бабынин** Александр Александрович; һөнәри эшчәнлектәге казанышлары һәм дәүләт хакимияте органнарында нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Премьер-министры ярдәмчесе **Җаббаров** Марат Фатыйх улы; театр сәнгатен үстерүгә зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен «В.И.Качалов исемендәге Казан академия рус зур драма театры» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе артисты **Иванова** Антонина Аркадьевна; «Казан дәүләт яшь тамашачы театры» дәүләт бюджет учреждениесе артисты **Язов** Дмитрий Леонидович; музей эшен үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Татарстан Республикасының Милли музее» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе генераль директорының фәнни-тикшеренү эше буенча урынбасары **Измайлова** Светлана Юрьевна; республиканың нефть сәнәгатен үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «МАКойл» акционерлык җәмгыяте генераль директоры **Ишкиниев** Дамир Азат улы; прокуратура органнарында күпьеллык намуслы хезмәте, законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытуга зур өлеш кертүе өчен Татарстан Республикасы Прокурорының Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнары белән хезмәттәшлек буенча өлкән ярдәмчесе **Кильганова** Анна Владимировна; финанс контроле өлкәсендә күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен Татарстан Республикасы Хисап палатасының экспертиза һәм методология идарәсе башлыгы – инспекторы **Мансурова** Лариса Федоровна; «Татарстан Республикасы «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлегенең Контроль-хисап палатасы» муниципаль казна учреждениесе рәисе **Шливе** Татьяна Владимировна; күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, татар милли мәдәниятен саклауга һәм үстерүгә зур өлеш кертүе өчен Бөтендөнья татар конгрессы республика иҗтимагый фондының баш референты **Мингәрәев** Илдар Камил улы; мәдәният һәм сәнгать өлкәсендәге казанышлары, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәренең «Нардуган» җыр һәм бию ансамбле» муниципаль бюджет учреждениесе директоры **Мосифуллин** Наил Шәкүр улы; производствода югары күрсәткечләргә ирешүе һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен «Казан дәүләт казна дары заводы» федераль казна предприятиесе 7 нче цехының 34 нче участогы механигы **Хәсәнова** Гөлчәчәк Хәбир кызы **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

* * *

«ТатКравтИнвест» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры **Кравцун** Валерий Анатольевичка, «СПС» төзелеш компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры **Шахов** Алибала Гаджигиреевичка, «ИТ-парк» югары технологияләр өлкәсендәге технопарк» дәүләт автоном учреждениесенең Казан технопаркы икенче мәйданчыгы җитәкчесе **Агалакова** Ольга Геннадьевнага; «АйСиЭл Софт» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең Кушымталар эшләү департаменты әйдәүче инженеры-программисты **Александрова** Елена Николаевнага; «АйСиЭл Софт» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең деск сервисы юнәлеше җитәкчесе урынбасары **Әхмәтҗанова** Регина Игоревнага; «Татарстан Республикасының Мәгълүмат технологияләре үзәге» Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесенең процессларны цифрлы нигездә үстерү идарәсе башлыгы **Борисова** Светлана Викторовнага; «АйСиЭл Софт» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең Кушымталар эшләү департаменты төркеме җитәкчесе **Зәкиева** Алсу Фәрит кызына; «Төбәк – мәгълүмат проектларына идарә» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең проектларга идарә бүлеге менеджеры **Климина** Динә Әскәр кызына; «АйСиЭл Софт» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең Россия заказчылары өчен сервислар эшләү хезмәте проектлар төркеме өлкән җитәкчесе **Николаева** Ольга Валерьевнага; «ИнноСистем» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең проектлар офисы проект җитәкчесе **Прыгунова** Ирина Викторовнага; «АК БАРС» акционерлык коммерциячел банкы (гавами акционерлык җәмгыяте) Мәгълүмат технологияләре департаментының ИТ хезмәте күрсәтү идарәсе кредит бирү процессларын автоматлаштыруны тәэмин итү бүлеге баш эксперты **Сергеева** Иветта Эдвиговнага; «СОФОЙЛ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры **Фәррахова** Рушания Ринат кызына; «БАРС Груп» акционерлык җәмгыятенең проектларга кадәрге әзерлек бүлеге җитәкчесе **Билалова** Ләйлә Сәедмуса кызына; «Россия телевидение һәм радиотапшырулар челтәре» федераль дәүләт унитар предприятиесенең «Татарстан Республикасының радио-телевидение тапшыру үзәге» филиалы баш юрисконсульты **Галиуллина** Тәнзилә Зөфәр кызына; «Төбәкара компетенцияләр үзәге – Казан мәгълүмат технологияләре һәм элемтә техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе укытучысы **Ильясова** Асия Бәхетбай кызына; «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесе Мәгълүмат технологияләре һәм интеллектуаль системалар институты директорының үсеш буенча урынбасары **Максимова** Ирина Александровнага; «Иннополис университеты» югары белем бирү автоном коммерциячел булмаган оешмасының Геомәгълүмат системалары үзәге җитәкчесе **Низамова** Диана Рьяс кызына; «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» акционерлык җәмгыяте генераль директорының федераль һәм Мәскәү хакимият органнары белән хезмәттәшлек буенча урынбасары – Мәскәү шәһәрендәге филиалы (хәбәрчеләр пункты) директоры **Газалиева** Динә Әлиф кызына; «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» акционерлык җәмгыяте генераль директорының мәгълүмати тапшырулар буенча урынбасары **Кадыйрова** Светлана Николаевнага; «Бөтенроссия дәүләт телевидение һәм радио тапшырулары компаниясе» федераль дәүләт унитар предприятиесенең «Татарстан» дәүләт телевидение һәм радио тапшырулары компаниясе» филиалы директоры урынбасары – телевидение мәгълүмати программалары хезмәте башлыгы **Нуриева** Диана Әнвәр кызына; «Россиянең сноуборд федерациясе» гомумроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан Республикасындагы төбәк бүлекчәсе тренеры **Белова** Эльвира Кәбир кызына; «Россиянең сноуборд федерациясе» гомумроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан Республикасындагы төбәк бүлекчәсе рәисе **Белов** Денис Фёдоровичка; «Россиянең трамплиннан чаңгыда сикерү һәм ике төрдәге чаңгы ярышлары федерациясе» гомумроссия иҗтимагый оешмасы президенты **Дубровский** Дмитрий Эдуардовичка; «Татнефть – Ак Барс» спорт-коммерциячел предприятиесе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең «Ак Барс» хоккей клубы баш тренеры **Квартальнов** Дмитрий Вячеславовичка; Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының «Спорт әзерлеге үзәге» дәүләт автоном учреждениесе спортның кышкы төрләре бүлеге спортның паралимпия төрләре буенча спортчы-инструкторлары: **Зәйнуллина** Марта Альфред кызына, **Миңнеголов** Рушан Рөстәм улына; «Алекс» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры урынбасары **Алексеев** Дмитрий Владимировичка; «Җәзаларны үтәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Казан интенсив күзәтүле махсуслаштырылган типтагы психиатрия хастаханәсе (стационар)» федераль казна учреждениесенең Сак бүлеге» федераль казна учреждениесенең куркынычсызлык бүлекчәсе кече инспекторы, эчке хезмәт өлкән прапорщигы **Антонов** Евгений Витальевичка; «Җәзаларны үтәтү буенча федераль хезмәтнең 16 номерлы медицина-санитария часте» федераль казна сәламәтлек саклау учреждениесенең 5 номерлы медицина часте» филиалы фельдшеры, отставкадагы эчке хезмәт өлкән лейтенанты **Хрусталева** Лариса Юрьевнага **Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәте** белдерелде.

Язучы фикере

Марат КӘБИРОВ

Янсын, әйдә...

Менә учыңа унлап илле сумлык аласың да бер сәгать тирәсе шуларга карап торасың. Ярты сәгать эчендә шуларның берсе чытырдап яна башлый. Учны да пешерми инде ул, бары тик күңелнең кайсыдыр җирендә уңайсыз бер хис кенә тудыра. Тагын ярты сәгать тирәсе узуга, икенчесенә ут каба. Аннан өченчесенә, дүртенчесенә... Шул рәвешле, учыңдагы биш йөз сум санаулы вакыт эчендә янып юкка чыга. Көлен өреп төшерим дип үпкәңне тутырып суласаң, теге акчаларның хәтта көле дә калмаган. Син тирән көрсенеп куярга гына мәҗбүр буласың. Менә шундый хәлләр. Моны мистика дип әйтергә дә, фокус дияргә дә мөмкиндер. Ләкин бу – чынбарлык.

Район үзәгендәге кибетләрдә йөрим. Эш кораллары карыйм инде мин. Вак-төяген шунда, үткерли, кисә, тишә, чаба торганын. Чөнки бүген авыл җирендә алардан башка яшәп булмый. Гомумән, авыл җирендә яшисең икән, эш коралларың үзеңнеке булырга тиеш. Элек кенә ул көрәкне бер күршедән, сәнәкне икенчесеннән алып тора идек. Хәзер алай түгел. Ниндидер нәрсә сорап керсәң, күршең иң башта сиңа хәер сорарга кергән бик фәкыйрь бер бәндәгә караган сыманрак караш ташлый. Шуннан елмайган сыман итеп, чүт кенә уйланып тора. «Ватылды бит әле ул, – дип авыр сулый аннан соң, – Фәлән-фәлән кешегә биреп торган идем, ватып кертте». Акылың булса аңлыйсың инде: икенче төрле корал сорасаң да, ул сиңа бирмәячәк. Чөнки хәзер дәвере бүтән. Үз коралың юк икән, син аны бүтәннәрдән сорап торырга да лаек түгелсең.

Искәрмәләр дә табыла. Югары очта бер гаилә яши. Ире дә, хатыны да эшләми инде аларның. Әниләренең пенсиясе килсә, шуны безнең чиновниклар бюджет акчасын бүлгән шикеллерәк итеп үзләштерәләр дә берничә көн бай булып яшәп алалар. Мондый чакта аларга якын бармалы түгел, алар янында үзеңне дөньяның иң ачы хәерчесе кебек тоясың. Алар алдында бөтен дөнья калтырап торырга тиеш кебек. Калтыраталар да! Хатыны бу мәсьәләдә аеруча оста инде...

Менә шуларның бер эш коралы да юк бугай. Көрәк-сәнәккә бер як күршеләренә керәләр. Балта-пычкыга – икенчеләренә. Үлән чабарга кирәк булса, өченче күршеләреннән триммер алып торалар. Хәтта чиләкләренә кадәр – кешедән. Шул рәвешле дөнья көтеп яталар, бер җирләре дә кителеп төшми. Ашыйлар, эчәләр, җырлыйлар, бииләр. Эшлиләр дә. Җир казырга кирәк булса, күршедән көрәк алалар. Бәрәңге утыртырга уйласалар – капчык. Корал-фәләнгә акча әрәм итмиләр, кыскасы. Менә шулай матур гына яшәп яткан чакта, әниләренең пенсиясе артыбрак килгән дә, болар үзләрен магнат кебек хис итеп, бөтен күршеләрен кимсетеп-рәнҗетеп ташлаганнар. Хатыны инде, бөтенесе белән дә ачы итеп талашып чыккан. Ә ире үз көрәген кире сорап кергән күршесенең ипи шүрлегенә менеп төшкән. Бу батырлык түгел инде, күршесе – инвалидлык пенсиясендә аның. Шушы кадәр кылангач, күршеләренең ачуы чыккан. Көрәк тә бирмиләр икән хәзер, сәнәк тә, башкасын да. Шуннан болар эш коралларын үзләре алырга уйлый башлаган. Кибетләр буйлап эзләп йөриләр. Иң арзанын эзлиләр, чөнки магнат кебек кыланган чакларында бөтен акчаларын диярлек бетергәннәр. Ә арзаны юк...

Моны мин бик яхшы беләм, чөнки үзем дә эш коралларын эзләп йөрим. Бер кибеткә керәм, сәнәк өч йөз илле сум тора. Арзанрагы юк микән дип, икенчесенә барсам – дүрт йөз. Шуннан, аптырап, теге кибеткә кире китәм. Һоп! Анда инде дүрт йөз иллегә менгән. «Тукта, теге дүрт йөзлеген генә алыйм, булмаса», – дип, кире борылсам – анда биш йөз. Шул рәвешле, сәгать саен диярлек бәяләр артып тора. Нәрсә алам дисәң дә шул чама. Мондый вакытта дәшми калу иң отышлысы икәнен белсәң дә күңел кычкыра:

– Янгын! Янгын! Акча яна!

Үзең генә дәшмәскә, телеңне тыярга тырышасың. Дөресе дә шул. Акырып-бакырып, дөнья болгатып йөргәнче, хәлдән чыгу юлын тавыш-тынсыз гына эзләргә кирәк. Мин шулай иттем. Һәм дөнья читендәге бер кибеттә иске бәядән сатылучы эш коралларына юлыктым. Җыйдым барсын да. Төянеп кайтып киләм. Тегеләр очрады. Зарланалар. Акчаларына туры килердәй бернәрсә дә тапмаганнар. Минем салпы якка салам кыстыралар:

– И, маладис инде син. Безгә дә биреп торырсың инде, берни дә ала алмадык бит, – диләр.

Корал бик жалкы түгел, канишны. Тик үзенең бернәрсәсе дә булмаган килеш күршеләре белән туктаусыз ызгышып торган кеше белән бик аралашасы килми. Үз балтасы булмаган адәм кеше балтасының кадерен белми ул.

Янсын, әйдә...

ЯКТЫ КИЛӘЧӘК ИЛЕ

«Татнефть» куйган канатлар

Биредә хыяллар чынга аша, сәләтлеләр ачыклана, дуслар табыла, иҗат мохите хөкем сөрә. «Татнефть» хәйрия фондының «Рухият» программасы гамәлгә куйган «Сандугач сайрар илем» фестивале гади бәйге генә түгел. Дистәләгән мең балага «канат чыгарырга» ярдәм иткән, туган ояларыннан «очып» киткәч тә ташламый торган аерым бер дөнья ул.

«Татнефть»нең «сандугач»лары белән аралашу, аларның берсеннән-берсе матур чыгышларын күзәтү, казанышлары белән танышу әнә шундый фикер калдырды. Балалар һәм үсмерләр иҗатына йөз тотучы «Сандугач сайрар илем» төбәк фестивале быел инде егерме бишенче мәртәбә уздырылды. Быелгы фестивальнең гран-при һәм махсус стипендия ияләрен бүләкләү тантанасында без дә булып кайттык.

Иҗат һәм дуслык бәйрәме

«Татнефть»нең «Рухият» программасы Татарстанның мәдәнияте, әдәбияты, сәнгате үсешенә ярдәм итү, сәләтле балаларны ачыклау, сәләтле яшьләргә даими рәвештә ярдәм күрсәтү, моннан тыш, әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә бәйгеләр уздыру, шуларның нәтиҗәләре буенча премияләр тапшыру кебек юнәлешләр буенча эшчәнлеген ел дәвамында алып бара. Нефть төбәге һәм, гомумән, республиканың мәдәни брендына әйләнгән «Сандугач сайрар илем» фестивале исә «Татнефть»нең күпсанлы проектлары арасыннан дәрте, рухы, яктылыгы белән аерылып торадыр, мөгаен. Яшьлек, балачак патшалык итә анда чөнки!

«Сандугач сайрар илем» 25 ел дәвамында Әлмәт, Азнакай, Алабуга, Бөгелмә, Аксубай, Түбән Кама, Зәй һәм «кара алтын» төбәгенең башка районнарыннан барлыгы 60 меңнән артык талантлы баланы җыеп өлгергән инде. Быелгы катнашучылар белән якыннан танышасыбыз килеп, сәхнә артына уздык. Тамаша башланырга бер сәгатьтән кимрәк вакыт калган, барысы да дулкынлана, әзерләнә... Гомумән, аларның сүзләренә караганда, бу фестивальгә әзерлек бик күп вакыт алдан башлана икән.

«Татнефть» матбугат үзәге фотолары

«Татнефть» компаниясе генераль директорының социаль үсеш буенча урынбасары Рөстәм Мөхәммәдиев «Рухият» программасы җитәкчесе Флюра Шәйхетдиновага мактау кәгазе тапшырды.

– «Сандугач сайрар илем» безнең өчен гади бәйге генә түгел. Без биредә ел саен тәҗрибә тупларга, таныш-белешләр белән очрашырга, яңа дуслар табарга дип киләбез. Көндәшләр... Юк, көндәш түгел инде алар, сәхнәдәшләр, дисәк, дөресрәк булыр. Алар барысы да әзерлекле, – дип сөйләде Азнакайдан килгән «Бәхет» төркеме кызлары.

Быел алар инде өченче мәртәбә фестивальнең төп бүләге – гран-прига лаек дип табылган. «Гала-концертта чыгыш ясау бәхетенә дә ия булдык. Төп бүләк кулларда булса да, дулкынлану хисе кимемәде», – диеште алар.

Аннан күзем зәп-зәңгәр күлмәк кигән сылу кызларга төште. Сигезәү иде алар, сигезенең дә кулында – скрипка. Әлмәт шәһәренең 3 нче санлы Балалар сәнгать мәктәбендә шөгыльләнүче «Vivo» скрипкачылар төркеме кызлары икән.

– Үзем бу фестиваль белән яхшы таныш булсам да, коллектив белән әле икенче тапкыр гына катнашуыбыз. Быел I урынга лаек булдык. Ләкин хикмәт җиңү яисә җиңмәүдә генә түгел. Дөрес, монда көндәшлек тә көчле, шуңа да без берничә ай алдан әзерләнә башлыйбыз. Ләкин «Сандугач сайрар илем» ул әле – бәйрәм дә. Иҗат, дуслык бәйрәме, – диде төркем җитәкчесе Эльза Шаһиәхмәтова.

Кадрлар «бишеге»

Сәхнәгә тәүге адымнарын «Сандугач сайрар илем»дә ясаган, «Татнефть» ярдәме белән канат ныгыткан, тормышларын сәхнә белән бәйләгән шәхесләр аз түгел. Араларында Татарстанның атказанган артистлары Айдар Сөләйманов, Эльмира Кәлимуллина, Наил Сәгъдиев, татар эстрадасы артистлары Мөнир Рахмаев, Алинә Прокофьева, Азат Кәримов һәм башкалар... Шунысы мөһим: бу фестивальдә үсеп, киләчәген иҗат белән бәйләргә теләк белдерүчеләр ел да ачыклана. Нәкъ шул нисбәттән сәнгать өлкәсендә белем алуларын дәвам иттерергә карар кылган иң яхшы катнашучылар өчен махсус стипендия дә булдырылган. Быел әлеге стипендия 10 катнашучыга – Полина Сывороткина, Анастасия Ермилова, Нәфис Шәйдуллин, Таңсу Миңнебаева, Азалия Рыжова, Андрей Волков, Илүсә Әхмәтова, Арина Антонова, Ислам Ногманов һәм Диләрә Кәлимуллинага тапшырылды.

«Татнефть» компаниясе генераль директорының социаль үсеш буенча урынбасары Рөстәм Мөхәммәдиев сүзләренчә, балалар бүгеннән үк сәнгать дөньясында кайный икән, киләчәгебез, һичшиксез, матур булачак.

– Әлеге фестиваль төгәл 25 ел элек Илсөяр Мәсгутовна Хәйруллина («Рухият»нең беренче башкарма директоры, «ВТ»ның элеккеге бүлек мөхәррире. – **Ред.**) идеясе белән башланып киткән иде. Аның тырышлыгы нәтиҗәсендә нефть төбәгендәге балалар иҗаты тагын да зуррак үсеш алды. Бүген исә аның эшен Флюра Мәгъдәновна Шәйхетдинова («Рухият» программасы җитәкчесе. – **Ред.**) дәвам итә. Гомумән, «Рухият» ул – «Татнефть» хәйрия фондының төп юнәлешләренең берсе. Ә «Рухият»нең төп проекты – «Сандугач сайрар илем». Билгеле, монда катнашучы балаларның барысы да киләчәктә профессиональ артист булачак, дигән сүз түгел. Ләкин безнең балалар иҗат белән шөгыльләнә, сәнгать дөньясында кайный икән, киләчәгебез матур булачак, – диде ул тантаналы чарада.

«Татнефть» хәйрия фонды директоры Ренат Мамин да, әлеге сүзләрне җөпләп, катнашучыларның барысы да мәдәният өлкәсен сайламаган очракта да, биредә туплаган тәҗрибәләре аларга тормышта кирәк булачак, диде.

– Ел саен әлеге фестивальдә ике меңләп кеше катнаша. Ә 2,5 мең «сандугач»ыбыз үз киләчәкләрен мәдәният белән бәйләп өлгерде. Кемдер профессиональ артист булды, кемдер белем бирү өлкәсен сайлады. Башкача әйткәндә, «Сандугач сайрар илем» – нефть төбәген һәм бөтен Татарстанны кадрлар белән тәэмин итүче «бишек» ул. Иҗат өлкәсен сайламаган очракта да, хәзерге вакытта алган белемнәре һәм күнекмәләре киләчәктә балаларга һичшиксез булышып кына торачак. Әлеге фестиваль тәүге тапкыр 1997 елда – илебез авыр чорлар кичергән чакта уздырылган. 25 ел дәвамында мондый вакытлар аз булмагандыр. Илебез нинди генә сынаулар белән очрашса да, балаларыбызның тынычлык, мәрхәмәтлелек һәм мәхәббәт хөкем сөргән үз «дәүләте» булды. Моның өчен «Татнефть» компаниясе җитәкчелегенә зур рәхмәтемне белдерәсем килә, – диде Ренат Мамин.

Кичә тәмамланып, гимн яңгыраганда фестивальнең символы – сандугач үзе дә күренде. Каяндыр сәхнә артыннан килеп чыкты да, катнашучыларны әйдәгәндәй, биеккә омтылды. Кошчык тимердән ясалган булса да, бәйрәмне гаять матур рухта тәмам итеп куйды.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

ПЕНСИЯДӘ ИКӘН УЛ РӘХӘТЛЕК!

Шөгыль

Арчада яшәүче Сәгыйдә Гаязова әнә шулай ди. 42 ел сатучы булган ханым, пенсиягә чыккач та, биш елдан артык эшли әле. Ялдагы рәхәтлекне белми әле ул. Хәзер менә өч ел эчендә, эштән туктап та, тик утырмыйча яшәп булганын аңлаган. Бар җиргә өлгерә Сәгыйдә апа. Кул эшенә дә вакыт таба, онык та карый, концертларга да йөри, спортны да үз итә, мәдрәсәдә дә белем ала.

– Һәрнәрсәгә теләк кирәк. Мин сәүдә эшен яратып башкардым. Халык белән аралашу җаныма рәхәтлек бирә иде. Моннан берничә ел элек кибетләргә кеше йөрми башлады. Ул чакта кинәт бәяләр күтәрелде, хезмәт хаклары артмады. Мин бит ике кибеттә эшләдем. Райпо системасы беткәч, зәркән кибетендә калдым. Кесәләр такырайган чакларда андый җиргә кеше йөрми шул инде, – ди ул. – Вазгыятьне аңласам да, төшенкелеккә бирелдем. Нишләргә дә белмим. Аралашу булмауны авыр кичердем. Шуннан кулыма җеп алдым. Башта оекбаш бәйләргә утырдым. Тик моның белән генә тынычланып булмаганны аңладым. Ниндидер зуррак әйбер бәйлисем килде. Интернеттан палас бәйләргә өйрәндем.

Баштарак Сәгыйдә апаның паласлары матур килеп чыкмый. Кайберләре тигез булмый, икенчесенең җепләре туры килми. Әмма тотынган эшен кире ташламый ул. Ничек итсә итә, бәйләргә өйрәнә. Паласны тукымалардан ясый. Моның өчен иске киемнәрне кисеп, җепкә әйләндерә. Аннары инде шулардан бәйли.

– Өч кыз үстердем. Шуңа да иске киемгә кытлык булмады. Кечкенә чакта үзем тегеп кидергән күлмәкләрдән җеп ясый идем. Аннары бәйләнгән күлмәкләргә тотындым. Бер паласка җиде күлмәк кереп китте. Аны сораучылар да булды. Чимал күп кирәк, эше күзгә күренми. Бәясен кыйммәт итеп куеп булмый. Шуңа да күбрәк якыннарым, өем өчен бәйләдем, – дип сөйли ул. – Остару җиткәч, пакетларга тотындым. Төрле төстәге пакетларны кисеп, җеп йомгагы ясыйм. Аннары буш вакытымда шуны палас итәм. Андыйларны мунча, парник өчен бәйләдем.

Сәгыйдә апа, эштән киткәч, Арча районының ветераннар советы рәисе ярдәмчесе булып эшли башлый. Мәдрәсәгә укырга керә. Быел инде тәмамлый да. Эштән иртәрәк китәсе калган икән, ди ул.

– Шундый рәхәт яшибез. Ялга чыккач, тормышым 100 процентка үзгәрде. Без элеккеге әбиләр түгел инде хәзер. Заманнан калышмыйбыз. Яшәүнең рәхәтен тоеп, картаерга ашыкмыйча гомер итәбез. Пандемия чорында да өйдә утырмадык, гел йөреп тордык.

Сәгыйдә апа, пенсиядә бөтенләй башкача яшәп була икән, дип сөенә. Күрше, танышларын да үзе белән барырга чакыра икән. Концертларга еш йөриләр. Һәр иртә йога белән шөгыльләнеп кайталар. Кышын чаңгыдан төшмәгәннәр, хәзер скандинавия таякларына тотынганнар.

– Кешенең буш вакыты булмаска тиеш. Шулай эшләсәң, авыруларга, борчуларга урын калмый. Син үзеңнең кирәклегеңне тоеп, белеп яшисең. Күңелгә рәхәтлек аласың. Мин әле җырлый да башладым. Элек белгән кешеләр, Сәгыйдә, җырлыйсыңмыни син, дип килеп эндәшә. Башта балалар үстердек, аннары, эш, дидек. Җырлыйсы килсә дә, булмады. Хәзер менә рәхәтләнеп җырлыйм. Буш вакытым калса, пешерәм. Анысы да – рәхәт эш, – ди ул. – Үземә сүз бирдем: барасы килгән җиргә барырга! Онык та карыйм, балаларыма да вакытым бар. Спорт белән шөгыльләнергә дә җай чыгып тора. Эшне яратсаң, ялкауланмасаң, бер дигән итеп яшәп була!

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 7066 данә
Гомуми тираж – 16091 данә

Газетага сертификат бирелде

Заказ 248

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ

420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

www.vatantat.ru

info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru

89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР

222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+